КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 апрель г.Казань № 328

«Татарстан Республикасының Аква-культура һәм умартачылык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Аквакультура һәм умартачылык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба - учреждение)бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына:

календарь көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә:

учреждениенең ликвидация комиссиясе составын раславга;

Учреждениене бетерү тәртибен һәм срокларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

учреждениене бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә учреждениенең бетерү процессында булуы турындагы мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен терки торган органга бирергә, шулай ук әлеге карарның закон белән билгеләнгән тәртиптә кабул ителүе турында белешмәләрне бастырып чыгарырга;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез мөлкәтен алга таба файдалану турындагы тәкъдимнәрне, шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документацияне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә Учреждениене бетерү нәтиҗәсендә азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр

бирүне тәэмин итәргә, шулай ук Учреждениене бетерү буенча законнарда каралган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдим иткән исемлек нигезендә, элек учреждениегә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен календарь көннәрдә исәпләнә торган 60 көн эчендә законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин